КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 26 гыйнвар г.Казань № 46

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы пропаганда концепциясен раслау турында» 2018 ел, 22 август, 694 нче карары белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы пропаганда концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планын раслау турында» 2019 ел, 23 апрель, 328 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы пропаганда концепциясен раслау турында» 2018 ел, 22 август, 694 нче карары белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы пропаганда концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планын раслау турында» 2019 ел, 23 апрель, 328 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 02 май, 550 нче, 2023 ел, 14 август, 978 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы пропаганда концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планы (алга таба - Чаралар планы);

2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы пропаганда концепциясен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген исәпләү методикасы.»;

әлеге карар белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы пропаганда концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

әлеге карарга 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы пропаганда концепциясен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген исәпләү методикасын өстәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 23 апрель, 328 нче карары
белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 26 гыйнвар,46 нчы
карары редакциясендә)

2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы пропаганда концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планы

| Т/с | Чара | Җаваплы башкаручы | Үтәү срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Матбугат релизлары җибәрү юлы белән басма, электрон һәм челтәр массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат тарату.<br>Интервью һәм матбугат конференцияләре оештыру.<br>Республика башкарма хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан коррупциягә каршы көрәш чаралары турында массакүләм мәгълүмат чараларына хәбәр итү | Республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Республика “Татмедиа” матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | квартал саен, 2030 елга кадәр |
| 2. | Коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә халыкны хокукый агарту буенча телетапшырулар циклын чыгаруны тәэмин итү | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | ел саен, 2028 елга кадәр (елына кимендә 12 тапшыру) |
| 3. | Җәмгыятьтә коррупциягә каршы түзеп тормаслык мөнәсәбәт формалаштыру һәм коррупциягә каршы көрәшне пропагандалау максатларында социаль юнәлешле мәгълүмат-аңлату һәм мәгълүмат-имидж видеоматериалларын республика телеканал- | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | ел саен, 2028 елга кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | ларында эшләүне һәм трансляцияләүне оештыру (Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә) | | |
| 4. | Массакүләм мәгълүмат чараларының һәм җәмәгатьчелекнең игътибарын коррупция проблемасына җәлеп итү, коррупция чагылышына бәйле хокук бозуларның нәтиҗәләрен халыкка аңлату, коррупциягә бәйле хокук бозуларны профилактикалау буенча гражданнарның актив позициясен булдыру, шулай ук гражданнарның коррупциягә каршы һәм хокукый дөньяга карашын формалаштыру максатларында коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләрен иң яхшы яктыртуга республика массакүләм мәгълүмат чаралары арасында махсус журналистлар конкурсы үткәрү | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникация-ләр агентлыгы | ел саен, 2028 елга кадәр |
| 5. | «События недели» – «Атна вакыйгалары» газетасында «Коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә хокукый агарту» темасына материалларны бастырып чыгаруны тәэмин итү | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникация-ләр агентлыгы | ай саен, 2028 елга кадәр |
| 6. | Республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары катнашында, күрсәтелгән органнар эшчәнлегенең ачыклыгына һәм үтә күренмәлелегенә ярдәм итү максатларында интервью һәм матбугат конференцияләре оештыру һәм уздыру | Республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Респуб-ликасы муниципаль берәмлек-ләрнең җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Республика “Татмедиа” матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | 2030 елга кадәр (елга кимендә 1 тапкыр) |
| 7. | Эшмәкәрләр белән профилактик эш, шул исәптән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча укыту семинарлары уздыру | Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшмәкәрләр хокук-ларын яклау буенча вәкаләтле | квартал саен, 2030 елга кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе (килешү буенча) | |
| 8. | Россия Федерациясе Торак кодексының нигезләмәләре, торак мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның хокуклары һәм бурычлары турында телепрограммаларда (телетапшыруларда) һәм радиопрограммаларда (радиотапшыруларда) яңалыклар сюжетлары әзерләүне, күпфатирлы йортлар белән идарә итүче оешмаларны тикшереп тору системасында басмаларда бастырып чыгару юлы белән халыкны тәэмин итү | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | даими, 2030 елга кадәр |
| 9. | Милли мәктәпләр укучыларының туган телләрендә «Юк» коррупция дибез!» темасына эшләрен һәм «Намуслы яшәргә кирәк!» балалар рәсемнәрен, һөнәри белем бирү оешмалары студентлары арасында «Закон сагында, коррупциягә каршы!» иҗади эшләрен кулланып иҗади күргәзмәләр үткәрү һәм тематик стендлар оештыру | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе (килешү буенча) | ел саен, 2028 елга кадәр |
| 10. | Мәгариф учреждениеләрендә хокукый белемнәрне тарату максатларында мәгариф учреждениеләренең профессор-укытучылар составы арасында Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру темасына фәнни-гамәли тикшеренү эшләре конкурсын үткәрү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе (килешү буенча) | ел саен, 2028 елга кадәр |
| 11. | Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү оешмалары студентлары, галимнәр һәм эшләүче яшьләр катнашында коррупциягә түземсез мөнәсәбәт формалаштыру, хокук аңын һәм хокукый культуры дәрәҗәсен күтәрү бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән фәнни-дискуссион, | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы | ел саен, 2028 елга кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | шулай ук мәгълүмати-агарту җәмәгать чаралары үткәрүгә дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алуларны тормышка ашыру | | |
| 12. | Татарстан Республикасының югары белем бирү оешмалары студентлары арасында коррупциягә каршы тәртип формалаштыру бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән махсус агитацион-җәмәгать чаралары циклы оештыру, шул исәптән коррупциягә каршы юнәлештәге социаль реклама конкурслары (видеоконкурс, плакатлар конкурсы, фотокросс һ.б.) үткәрү. Әлеге эшләрне кулланып тематик стендлар оештыру һәм күргәзмәләр үткәрү | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы | даими, 2028 елга кадәр |
| 13. | Яшьләр оешмалары эшчәнлеген һәм үткәрелә торган иҗади конкурсларны яктырту максатларында мәгълүмат әзерләү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе (килешү буенча), Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | ярты елга бер, 2030 елга кадәр |

______________________